РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ АЛЕКСАНДРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛЕКСАНДРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

РЕШЕНИЕ — КАРАР

25.11.2024ел. — № 117

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 338-ФЗ номерлы Федераль законның 1 абзацы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 08.08.2024 N 232-ФЗ номерлы Федераль закон, Сарман муниципаль районының «Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Александровка авыл җирлеге Советы нигезендә карар иттем:

1. Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлегенең 2022 елның 14 февралендәге 41 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Җирле үзидарә органы җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, мәнфәгатьләр конфликтын төшереп калдыру максатларында җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары әлеге органның сайланулы профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен алар тарафыннан тиешле вазыйфаны биләү чорында тапшыра алмый.»;

2) 9.3 пунктның 5 пунктчасында «һәм квалификация турында»сүзләрен төшерергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Александровка авыл җирлеге
Советы рәисе И.Ф.Вафин